# ПРОЛОГ

*...Күпме авыллар үтелгән,*
*Берсе дә Кырлай түгел.*

*Сибгат Хәким*

*Казан арты төбәге, аеруча Кырлай авылы – Тукайны шагыйрь иткән шартларның иң әһәмиятлесе. Ак киндер алъяпкычлы, киндер бияләйле, татарча бүрек кигән эшчән Сәгъди абзый – Тукайга рухи азык биргән тыйнак, эшлекле татар крестьяннарының иң олы җанлысы. Кырлай тирәсе – бөтен буа-чишмәләре, кара урманнары, уен-җырлары, йолалары белән – Тукай шагыйрьгә үз гомеренә җитәрлек рухи азык биргән.*

*Мөхәммәт Мәһдиев*

*1953 елның сентябрендә мин Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Бераздан безне, яңа студентларны, Арча районы Сәрдәбаш авылына колхоз бәрәңгесен алышырга җибәрделәр. Анда бер ай чамасы эшләгәч, йөк машинасына төялеп, Казанга кайту өчен, Арча станциясенә юл алдык. Шунда миңа, машина әрҗәсеннән карап кына булса да, беренче мәртәбә Кырлай авылы аша үтеп китәргә насыйп булды.*

*Без Арчага кайтып бара идек,*
*Машинабыз узды Кырлайдан,*

*«Кеп-кечкенә Апуш[1]-Кырлай» хәзер*
*«Тукай-Кырлай[2]» булып зурайган.*
*Башладылар кызлар «Туган тел»не,*
*Җыр уятты нечкә хисләрне.*
*Кырлай урманнары!*
*Әле дә сездә*
*«Былтыр-егет» утын кисәме?!*

*Кырлай![3] Синдә шагыйрь «бу дөньяга*
*Иң беренче ачкан күзләрен».*
*Урамнарың, чирәм белән төреп,*
*Саклый аның баскан эзләрен.*

*...Менә Сәгъди[4] йорты. Бөдрә каен,*
*Йөрәк түзми,*
*Ярсый,*
*Ашыга,*
*Ачылыр да капка, Тукай үзе*
*Чыгып басар кебек каршыга...*

*Озатып калды безне җырчы каен,*
*Селки-селки алтын чукларын,*
*Күңел көтте,*
*Көтте өметләнеп,*
*Ә син, шагыйрь, никтер чыкмадың.*

---

[1] *Апуш* – кечкенә Габдулланы якын күреп, үз итеп мөрәҗәгать иткәндә әйтелгән исем.

[2] *«Тукай-Кырлай»* – шушы авылда оештырылган колхоз исеме.

[3] «Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга, андагы хатирәләрдә озаграк туктарга тугры килде», – дип яза Тукай «Исемдә калганнар» әсәрендә. Шагыйрь монда, әлбәттә, Кырлайда мәдрәсәгә йөри башлавын, укырга-язарга өйрәнүен күздә тота (*Тукай Г.* Әсәрләр : 4 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1977. – 4 т. – 23 б.).

[4] *Сәгъди* – Сәгъдетдин Шәмсетдин улы Салихов (1837–1904), ятим Габдулланы уллыкка алган олы җанлы Кырлай авылы кешесе.

*Белмәдең шул: безнең сине сагынып,*
*Кырлай аша җырлап үтәсен,*
*Белдең ләкин «көчле, зур халкыңның»[1]*
*Сине мәңге хөрмәт итәсен…*

*Без Арчага кайтып барган чакта*
*Узып киттек «Тукай-Кырлай»дан,*
*Моңлы бер җыр булып күңелләрдә*
*Урын алган тугай-кырлардан.*

*Казанга кайткач, мин берәр көн шушы шигырь белән мәшгуль булдым. Анда Тукай рухы ныграк сизелсен диптер инде, шагыйрьнең үз сүзләрен, үз гыйбарәләрен кулланырга тырыштым. Шигырьне Уфада нәшер ителә торган «Кызыл таң» редакциясенә җибәрдем. Ул 1954 елның 15 апрель санында басылып та чыкты.*

*«Узып барышлый» шигыренең матбугатта чыгуы миңа Тукайның канатлы әйтелмәләренә җитдирәк, тирәнрәк каравым өчен бер этәргеч булды. Алар турында мин университет профессоры Вахит Хаков белән бергә Татарстан радиосы аша алып бара торган «Тел күрке сүз» тапшыруларында сөйли башладым. «Мәдәни җомга» газетасында регуляр алып барыла торган «Гыйбарәләр тарихына сәяхәт» рубрикасы астында фәнни-популяр мәкаләләр бастырдым. Бүгенге көндә, шушы материалларны туплап, тәртипкә китереп, шагыйрьнең 130 еллыгы уңае белән махсус бер җыентык төзедем.*

---

[1] «*Көчле, зур халкыңның*» – әлеге шигырь юлы Г. Тукайның 1940 елның 15 апрелендә «Шәрык клубы»нда укыган «Халык әдәбияты» лекциясендәге канатлы әйтелмәдән («…халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул») файдаланып язылды (*Тукай Г.* Әсәрләр : 4 томда. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1977. – 4 т. – 267 б.).

## ТАРИХТАН БЕР СӘХИФӘ

Бөек әдипләрнең халыктагы популярлыгы нәрсәләрдә күренә? Әлбәттә, аларның әсәрләре миллионнар тарафыннан йотылып укылу моның төп күрсәткече булып тора. Тагын шиксез-бәхәссез бер дәлил шул: яраткан шагыйрьләренең күп кенә әсәрләрен яисә алардан аерым өзекләрне халык яттан белә. Соңгыларын тапкыр һәм тирән мәгънәле гыйбарәләр сыйфатында ул үзенең сөйләм телендә дә бик еш куллана; алар ярдәмендә тормыштагы төрле-төрле вазгыятьләргә бәя бирә, вакыйгаларга, фактларга үзенең мөнәсәбәтен белдерә.

Әдәби чыганаклардан сөйләмә яки язма телгә күчкән әнә шундый өзекләр, цитаталар «канатлы әйтелмәләр» дип атала*. Аңлашыла ки, халык хәтеренә кереп урнашкан мондый гыйбарәләрнең зур күпчелеге классик язучылар иҗатыннан «очып чыкканнар». Мәсәлән, Н. С. Ашукин һәм М. Г. Ашукина тарафыннан төзелгән «Крылатые слова» сүзлегенә А. С. Пушкин әсәрләреннән — 98, А. С. Грибоедовтан — 61, Н. В. Гогольдән — 54, И. А. Крыловтан 47 канатлы сүз кертелгән. Болар — Ашукиннар сүзлегендәге иң югары күрсәткечләр.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай — татар телен канатлы сүз-тәгъбирләр белән баетуга аеруча зур өлеш керткән әдип. Аның иҗатының бу хасиятенә тел-әдәбият белгечләре әле узган гасыр башларында ук игътибар иткәннәр иде.

---

* Әдәбият белеменә бөек алман шагыйре Иоганн Вольфганг фон Гёте керткән атама.

Менә шуңа ачык бер мисал. Казандагы «Мәгариф» китапханәсе нәшрияты 1913 елда «Тукай сүзләре» исемле гадәти булмаган бер җыентык бастырып чыгара. (Аның икенче басмасы – 1915, өченчесе 1920 елда дөнья күрә.) Китапның исеме астында «Тукайның афоризмнары – халык мәкальләре урынында йөртелерлек вә йөртелә торган сүзләре» дигән аңлатма бирелгән һәм «Җыючысы – Г. Шәрәф» дип күрсәтелгән.

Бу җыентыкның дөнья күрүендә танылган җәмәгать эшлеклесе, нәшир Гыйльметдин Шәрәфнең (1885–1942) роле зур булган. Мәшһүр зыялыларыбыз – бертуган Шәрәфләрнең өченчесе, ул 1906 елда Казанда «Матбагаи Шәрәф» басмаханәсен ача һәм аңа җитәкчелек итә, Тукайның берничә җыентыгын бастыра. Хакимият эзәрлекләүләре аркасында басмаханә 1911 елда ябыла, әмма ике елдан аның эшчәнлеге «Мәгариф» исеме белән кабат торгызыла. Хәлбуки «Тукай сүзләре» җыентыгын чыгаруда Гыйльметдин башлыча нәшир сыйфатында катнашкан булырга тиеш. Ни өчен дигәндә, бу китапның өченче басмасында «Җыючысы – Җан Шәрәф» дип төгәл күрсәтелгән. Димәк, Тукай сүзләрен туплаучы – Шәрәфләрнең дүртенчесе һәм иң кечесе, соңрак сәяси эшлекле, тел галиме һәм язучы буларак киң танылган Галимҗан Шәрәф (1896–1950) икән. Сүз уңаеннан искәртеп үтик, китапның беренче һәм соңгы басмаларында төзелеш һәм эчтәлек ягыннан аерма күренми, бары тик аңа керешләрдә генә гарәп-фарсы алынмаларын татарның үз сүзләре белән алмаштыру юнәлеше ачык сизелеп тора.

«Тукай сүзләре» җыентыгына «Нәширләрдән» дигән баш астында бирелгән кереш сүз җитди игътибарга лаек. Анда Тукай шигъриятенең фәлсәфи-афористик рухы бик дөрес тотып алынган:

«Тукаев шигырьләренең мәгънә җәһәтеннән тирәнлеге, самимилеге вә теле җәһәтеннән матурлыгы тугърысында